ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

15.02.2021 Олы Кайбыч ав. № 59

«2021-2024 елларга Кайбыч муниципаль районында әйләнә-тирә мохитне саклау» муниципаль программасын раслау турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

1. Кушымта итеп бирелә торган «2021-2024 елларга Кайбыч муниципаль районында әйләнә-тирә мохитне саклау» муниципаль программасын расларга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының мәгълүматый-телекоммуникацион Интернет челтәрендәге http:// kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча рәсми сайтында урнаштырырга һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга.
3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2021 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесенең төзелеш һәм ТКХ буенча урынбасары Ф.Ш. Әхмәтовка йөкләргә.

Җитәкче А.Н.Макаров

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Башкарма комитетының
2021 елның 15 02
59 номерлы карары белән
расланган

# «2021 - 2024 ЕЛЛАРГА КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНДА ӘЙЛӘНӘ-ТИРӘ МОХИТНЕ САКЛАУ» МУНИЦИПАЛЬ ПРОГРАММАСЫ

**Олы Кайбыч, 2021ел**

## ПРОГРАММА ПАСПОРТЫ

| | |
|---|---|
| Программа атамасы | «2021-2024 елларга Кайбыч муниципаль районында әйләнә-тирә мохитне саклау» муниципаль программасы |
| Программа эшләүгә нигез | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 28 декабрендәге 1083нче карары белән расланган «Татарстан Республикасының әйләнә-тирә мохитне саклау, табигать ресурсларын торгызу һәм алардан файдалану» дәүләт программасы |
| Программаның заказчы-координаторы | Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советы, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты |
| Программаның төп эшләүчеләре | Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты |
| Программаның максаты | Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында гражданнарның экологик иминлеге дәрәҗәсен арттыру, табигать ресурсларын саклау һәм алардан нәтиҗәле файдалану |
| Программаның бурычлары | Комплекслы һәм рациональ файдалану принципларында район икътисады ихтыяҗларын табигать ресурсларының төрле төрләрендә тәэмин итү;<br>табигать ресурсларын әйләнә-тирә табигать мохите компонентлары буларак саклау һәм торгызу чараларын гамәлгә ашыру;<br>районда экологик хәлне тотрыкландыру һәм аны яхшырту;<br>житештерү һәм куллану калдыклары белән районның әйләнә-тирә мохитен пычрату дәрәҗәсен киметү;<br>су ресурсларыннан рациональ файдалану. |
| Программаны гамәлгә ашыру вакыты | 2021-2024 еллар |
| Программаны чыганаклары | ТР бюджеты чаралары;<br>Район бюджеты акчалары;<br>Башка чыганаклар;<br>Бюджеттан тыш чыганаклар. |
| Финанслау күләмнәре | (таблица астарак) |

| ел | Чаралар күләме, мең сум | | | |
|---|---|---|---|---|
| | ТР бюджетыннан | район бюджеты | Башка чыганаклар | Бюджеттан тыш чыганаклар |
| 2021 | | 719,5 | 633,0 | 2392,0 |
| 2022 | 8000,0 | 719,5 | 1196,0 | 4644,0 |
| 2023 | 7000,0 | 719,5 | 1042,0 | 4028,0 |
| 2024 | | 719,5 | 555,0 | 2080,0 |
| барысы | 15000,0 | 2878,0 | 3426,0 | 13144,0 |

Татарстан Республикасы бюджетыннан бүлеп бирелә торган акчаларның суммасы чираттагы финанс елына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы нигезендә ел саен ачыкланачак.

Җирле бюджеттан финанслау күләме чираттагы финанс елына муниципаль район бюджеты кабул ителгәндә ел саен билгеләнә.

| | |
|---|---|
| Көтелгән соңгы нәтиҗәләр | Атмосфера һавасына зарарлы матдәләр чыгаруларның, пычранган агып төшүче суларны су объектларына һәм җыела торган калдыклар күләмнәренең кимүе; |

| | |
|---|---|
| | районда экологик хәлне савыктыру, табигать ресурсларының һәм әйләнә-тирә табигать мохитенең торышына комплекслы йогынты ясау системасын гамәлгә ашыру;<br>җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итүне муниципаль җайга салу системасын булдыру, кешенең яшәү тирәлеген һәм аның эшчәнлек шартларын яхшырту;<br>дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары һәм табигатьтән файдаланучылар арасында үзара хезмәттәшлекнең нәтиҗәлелеген арттыру;<br>халыкның экологик аңын һәм экологик әһәмиятле социаль нормалар формалаштыру. |

## 1. Программаны гамәлгә ашыруның гомуми характеристикасы, төп проблемалары һәм өлкәне үстерү фаразы

Соңгы вакытта дәүләт дәрәҗәсендә дә, иҗтимагый аңда да цивилизациянең алга таба үсеше, табигый рәвештә, табигатькә кертелә торган үзгәрешләргә карамыйча, гадәтләнгән дәрәҗәдә фәнни-техник прогрессның алга таба үсеше еш кына кире кайтарылмый торган, куркыныч, ә бәлки, фаҗигале нәтиҗәләргә китерәчәген, барыннан да элек, кешенең үзе өчен планетаның иң мөһим биотик өлеше булуын аңлау ныгый. Татарстан Республикасының социаль-икътисадый, хуҗалык һәм экологик бурычларны балансны хәл итүне гамәлгә ашыручы озак вакытлы экология сәясәтенең фәнни нигезе булып Татарстан Республикасының табигатьтән нәтиҗәле файдалануга һәм әйләнә-тирә табигать мохитенә тискәре йогынтыны киметүгә юнәлдерелгән тотрыклы үсешкә күчү концепциясе тора.

Кайбыч районында әйләнә-тирә мохитне саклау һәм табигать ресурсларыннан нәтиҗәле файдалану мәсьәләсе аеруча әһәмияткә ия. Соңгы елларда өлгереп җиткән экологик проблемалар спектры аларны хәл итү һәм Кайбыч районы территориясенең табигый-тарихи потенциалының регенератив мөмкинлекләрен саклау өчен кичектергесез һәм комплекслы якын килү таләп итә, ә җәмгыятнең сәламәтлеге һәм байлыгы моның белән бәйле.

## 2. Кайбыч районында әйләнә-тирә мохит торышына анализ

Кайбыч районы халкы саны - 13 мең 415 кеше. Шул исәптән татарлар - 67.5%, руслар - 26.5 %, чувашлар - 5.2 % һәм башка милләт вәкилләре - 0.8 %.

Кайбыч районы Татарстан Республикасының көнбатышында урнашкан. Идел буе икътисадый районына керә. Апас, Югары Ослан, Яшел Үзән районнары һәм Чуваш Республикасы белән чикләшә.

Район үзәге - Олы Кайбыч авылы, анда 1 мең 800 кеше яши. Район буенча Зөя, Гөбнә, Бәрле, Ырым елгалары ага, Горький тимер юлы уза ( Колаңгы станциясе).

Районда 57 торак пункт. 31 крестьян-фермерлык хуҗалыгы (КФХ), 3 крестьян кооперативы (ССППК), 9 җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятьнең авыл хуҗалыгы предприятиесе (ҖЧҖ), шул исәптән 3 эре агрофирма. Районда сабан бодае, көзге арыш, арпа, солы, борчак, шикәр чөгендере үстерәләр. Терлекчелекнең төп тармаклары - ит-сөт җитештерү, ат үрчетү һәм сарык асрау.

### Атмосфера һавасы торышы һәм аны саклау

Районның 6 предприятиесендә 52 стационар чыганак эшли, алардан атмосферага ел саен 0.020 мең тонна зарарлы матдә чыгарыла.

Һаваны төп пычратучылар - каты матдәләр, углерод оксиды. Атмосфера һавасын пычратуга төп өлешне тармаклар предприятиеләре (%): азык-төлек – 20, агросәнәгать - 75.5 кертә.

### Һаваны саклау чараларының үтәлеше турындагы белешмәләр.

Күпфатирлы 4 торак йорт һәм социаль-мәдәни көнкүреш объектлары индивидуаль җылытуга күчерелгән.

**Су ресурсларының торышы, аларны саклау һәм алардан файдалану**

Ырым, Гөбнә, Бәрле, Зөя елгаларының пычрану чыганаклары булып район предприятиеләреннән, сәнәгать мәйданчыкларыннан һәм торак пунктлар территорияләреннән җитәрлек дәрәҗәдә чистартылмаган суларны агызу тора. Моннан тыш, кече елгалар суларында азотлы һәм органик кушылмаларның күп булуы авыл хуҗалыгы җирләрендә азотлы ашламалар куллану, элек төзелгән терлекчелек фермаларын урнаштыру кагыйдәләрен үтәмәү, су саклау зоналарында терлекләр көтү нәтиҗәсе булып тора.

**Су объектларына ташланган пычрак матдәләр массасы, т**

| Муници-паль район | БПК | Үлчәнгән матдәләр | нефть продукт-лары | Гомуми фосфор | сульфатлар | хлоридлар | азот аммон | нитратлар | нитритлар | СПАВ | фосфатлар | марганец | хром | цинк | медь |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Кайбыч | 2,4 | 42,1 | | | 149 | 27,1 | | | | | 0,36 | | | | |

## 2.2. Җитештерү һәм куллану калдыклары.

Олы Кайбыч авылыннан 2км көнбатыштарак урнашкан каты көнкүреш калдыклары полигоны бар. Каты көнкүреш калдыклары полигонының проект куәте - 60 мең м3, эксплуатацияләүнең исәпләннгән срогы - 20 ел. Полигонга бару юлы асфальтланган. Мәйданы 6 га. Санитар-саклау зонасы канәгатьләнерлек хәлдә.

**Калдыклар барлыкка килү турында белешмәләр, елына мең тонна**

| Барлык калдыклар | терлекчелек | көнкүреш | Сәнәгать, шул исәптән | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | Барлыгы | 1 класс | 2 класс | 3 класс | 4 класс | 5 класс |
| **Кайбыч МР** | | | | | | | | |
| 108,995 | 103.74 | 5,1 | 0.078 | 0 | 0 | 0.004 | 0,006 | 0.067 |

**2020 елды каты көнкүреш калдыклары полигонының вакытлыча саклау мәйданчыгына кабул ителгән калдыклар массасы, мең т**

| Полигон (чүплек) урнашкан урын | Калдыклар саны | | |
|---|---|---|---|
| | Торак сектор | Предприятие һәм оешмалар | Барлыгы |
| Каты көнкүреш калдыклары полигоны | 4,5 | 0,6 | 5,1 |

## 2.3. Җир ресурсларының торышы, аларны саклау һәм алардан файдалану.

Кайбыч муниципаль районының җир фондының гомуми мәйданы 99,6 мең га тәшкил итә. Җир фонды структурасында, район Җир кадастры хезмәтенең исәпкә алу мәгълүматлары буенча, төп өлеш авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләргә туры килә - 68,4 мең га, торак пунктлар җирләре 3,2 мең га, урман фонды җирләре 27,4 мең га, сәнәгать җирләре 0,6 мең га тәшкил итә.

**2020елның 1нче гыйнварына авыл хуҗалыгы предприятиеләренең сөрү җирләренең мәйданнары турында белешмәләр (мең га)**

| Муниципаль район | Авыл хуҗалыгы җирләренең гомуми мәйданы | Сөрүлекләр мәйданы | Сөрелү торышы<br>% |
|---|---|---|---|
| Кайбыч | 66,3 | 56.4 | 85,0 |

Туфрак деградациясеү проблемалары арасында беренче урында эрозия тора. Аның төп сәбәбе - агроландшафтны оештыруны бозуда, ә атап әйткәндә, сөрүлек, болын һәм урман җирләренең дөрес булмаган нисбәтендә.

**2020 елның 1 гыйнварына авыл хуҗалыгы предприятиеләренең чәчүлек җирләренең эрозияләнүе турында белешмәләр**

| Муниципаль район | Сөрә җире мәйданы | Эрозия бара | % | Площадь пашни | Подверже но эрозии | % |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | 2015 ел | | | 2020 ел | | |
| Кайбыч | 56,5 | 21.8 | 38,6 | 56,4 | 23,5 | 41,7 |

Эрозия деградациясенең соңгы стадиясе - район авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге яңа җирләрдә чокырлар барлыкка килү. Чокырларның мәйданы 617 гектар тәшкил итә, алар 608 га мәйдан били, шундый чокырлар - 501 данә.

Соңгы елларда органик ашламаларны туфракка кертү күләмнәре һәм нормалары кинәт кыскаруга бәйле рәвештә туклану элементларының тискәре балансы да үсә, бу туфракның уңдырышлылыгына сизелерлек йогынты ясый. Туфракта гумус һәм минераль тукландыру элементларын дисбалансланауны бетерү туфракның уңдырышлылыгын саклау һәм торгызу һәм югары тотрыклы уңыш алу өчен төп бурыч булып тора.

**2020 елның 1 гыйнварына бозылган җирләрнең мәйданнары турында белешмәләр (га)**

| Муниципаль район | Сәнәгать эшкәртүе карьерлары | | Эчке хуҗалык карьерлары | | Җирлек территория-ләрендәге карьерлар | | Үз белдеге белән эшләнә торган карьерлар | | Төзекләндерелгән карьерлар | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | саны (данә) | мәйданы | саны (данә) | мәйданы | саны (данә) | мәйданы | саны (данә) | мәйданы | саны (данә) | мәйданы |
| Кайбыч | 3 | 20 | - | - | - | - | - | - | 1 | 2.09 |

**Үсемлекләр дөньясы.**

Районның үсемлек капламы - нигездә, табигый һәм ясалма төзелгән үсемлекләр берләшмәләре, катнаш урманнар һәм болын далалары, көтүлекләр, авыл хуҗалыгы культуралары. Табигый азык җирләре һәм болыннары үсемлекләрнең түбәндәге төрләре очрый: гади меңьяфрак, зур бака яфрагы, тар яфраклы йонча, болын солычасы, кызыл солыча, сарут һәм башкалар.

Субүлүләрнең һәм балчыкларның сөзәк һәм текә битләрендә, тигезлекләрдә вак кыяклы һәм төрле үлән-кыяклы үсемлекләр берлекләре өстенлек итә, аларда тар яфраклы йонча, солыча, кырчыл өстенлек итә.

Үсемлекләр капламының торышы һәркайда ярлыланган дип бәяләнә, чөнки көтүлекләрдә, нигездә, үсемлекләрнең югары деградацияләнүе дәрәҗәсе турында дәлилләүче кымызлык, бака яфрагы, билчән, шайтан таягы үсә.

**Территориянең урманнары**

| Муниципаль район | Районның гомуми мәйданы | Урман мәйданнары | Урманлылык, % |
|---|---|---|---|
| Кайбыч | 99,6 | 27,4 | 27,5 |

**Җирлекләрнең яшел фонды.** Ел саен районның коммуналь хезмәтләре һәм оешмалары тарафыннан район бистәләрен яшелләндерү эшләре алып барыла. Ел саен әлеге хуҗалыклар көче белән чыршы, юкә, каен, пирамидаль тополь кебек 5000 артык төрле агач һәм куак үсентесе утыртыла. Чәчәклекләр яшелләндерүнең төп элементларыннан берсе булып тора. Чәчәкле яшелләндерүнең алымнары күптөрлелеге белән аерылып тора.

## 3. Программаның максатлары һәм төп бурычлары

Әлеге программаның максаты - әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә бердәм дәүләт сәясәте булдыру, шулай ук Кайбыч муниципаль районының табигый мохитен торгызуга, саклауга һәм аның сыйфатын яхшыртуга юнәлтелгән конкрет чараларны гамәлгә ашыру. Куелган максатларга ирешү түбәндәге бурычларны хәл итү юлы белән тәэмин ителергә мөмкин:

- әйләнә-тирә мохит мониторингын һәм оештыру-оператив идарә итү системасын камилләштерү;
- әлеге программага кертелгән чараларны этаплап гамәлгә ашыруны, үз вакытында һәм максатчан финанслауны, акчаларны тиешенчә файдалануны тәэмин итү;
- халыкның барлык катламнарында гомуми экологик белем бирү сәясәте үткәрү.

## 4. Программаны ресурслар белән тәэмин итү

Программа проектында түбәндәге финанслау чыганаклары каралган: РФ бюджеты, республика бюджеты, район бюджеты, предприятиеләр һәм оешмалар акчалары, башка чыганаклар.

Табигатьне саклау объектлары төзелешенә капитал кертемнәр күләмнәре һәм Кайбыч муниципаль районының әйләнә-тирә мохитен савыктыру чараларын үтәүгә бәйле башка чыгымнар район бюджеты һәм башка чыганаклар исәбеннән ел саен аларны тиешле елга кабул иткәндә төгәлләштерелергә тиеш.

Программа иң өстенлекле юнәлешләр буенча районның экологик торышын исәпкә алып формалаштырылды. Гомумән алганда, 2021 - 2024 елларга программаны гамәлгә ашыру өчен ел саен 8442,0 мең сум күләмендә финанслау кирәк.

**«2021 - 2024 елларга Кайбыч муниципаль районы әйләнә-тирә мохитен саклау» муниципаль программасы чаралары**

| № п/п | Чара | Башкаручы | Срогы | Эшләр бәясе (сең сум) | | | | Финанслау чыганагы | Көтелгән нәтиҗә |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2021 | 2022 | 2023 | 2024 | | |
| **1. Оештыру эшләре** | | | | | | | | | |
| 1.1 | Табигатьне саклау эшчәнлегенең өстенлекле юнәлешләре буенча муниципаль районның норматив актларын эшләү | Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты | 2021 - 2024 | | | | | - | |
| 1.2 | Муниципаль районда табигатьтән файдалану һәм санитар-эпидемиологик иминлек комиссиясе эшен оештыру | Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты | 2021 - 2024 | | | | | - | Комиссия эше планын тормышка ашыру |
| 1.3 | «2025-2030 елларга муниципаль районның әйләнә-тирә мохитен саклау» концепциясен һәм муниципаль программасын эшләү | Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты | 2024 | | | | | - | Муниципаль программа |
| **2. Техноген йөкләнешләрне киметү буенча табигатьне саклау чараларын гамәлгә ашыру чаралары** | | | | | | | | | |
| **2.1. Атмосфера һавасын савыктыру һәм саклау гамәлләре** | | | | | | | | | |
| **2.2. Су ресурсларыннан нәтиҗәле файдалану һәм су объектларын саклау чаралары** | | | | | | | | | |
| **2.2.1. Халыкны чиста эчәргә яраклы су белән тәэмин итү чаралары** | | | | | | | | | |
| 2.2.1.1 | Каптажлы чишмәләрне һәм скважиналарны лицензияләү | Район авыл җирлекләре башкарма комитетлары (килешү буенча) | 2021-2024 | 1400,0 | 1400,0 | 1400,0 | 1400,0 | Бюджеттан тыш чыганаклар, башка чыганаклар | Халыкны сыйфатлы эчәргә яраклы су белән тәэмин итү |
| 2.2.1.2 | Олы Урсак авылында чишмә юлын чистарту | Олы Урсак авыл җирлеге Башкарма комитеты | 2022 | | 30,0 | | | Бюджеттан тыш чыганаклар, башка чыганаклар | Халыкны чишмә суы белән тәэмин итү |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 2.2.1.3 | Кече Мәми сважинасын тирәнәйтү | Кече Мәми авыл җирлеге Башкарма комитеты (килешү буенча) | 2021 | 80,0 | | | | Бюджеттан тыш чыганаклар, башка чыганаклар | Халыкны сыйфатлы эчәргә яраклы су белән тәэмин итү |
| 2.2.1.4 | Мөрәле авылында чишмә төзекләндерү | Мөрәле авыл җирлеге Башкарма комитеты (килешү буенча) | 2022 | | 50,0 | | | Бюджеттан тыш чыганаклар, башка чыганаклар | Халыкны сыйфатлы эчәргә яраклы су белән тәэмин итү |
| 2.2.1.5 | Иске Тәрбит авылында чишмә төзекләндерү | Иске Тәрбит авыл җирлеге Башкарма комитеты (килешү буенча) | 2022 | | 70,0 | | | Бюджеттан тыш чыганаклар, башка чыганаклар | Халыкны сыйфатлы эчәргә яраклы су белән тәэмин итү |
| 2.2.1.6 | Чистые Ключи п-да чишмә төзекләндерү | Надеждино авыл җирлеге Башкарма комитеты (килешү буенча) | 2021 | 10,0 | | | | Бюджеттан тыш чыганаклар, башка чыганаклар | Халыкны сыйфатлы эчәргә яраклы су белән тәэмин итү |
| 2.2.1.7 | Кече Кайбыч авылында чишмә төзекләндерү | Ябалак авыл җирлеге Башкарма комитеты (килешү буенча) | 2023 | | | 30,0 | | Бюджеттан тыш чыганаклар, башка чыганаклар | Халыкны сыйфатлы эчәргә яраклы су белән тәэмин итү |
| 2.2.1.8 | Олы Тәрбит һәм Чүти ав. чишмәләрне чистарту | Чүти авыл җирлеге Башкарма комитеты (килешү буенча) | 2021-2022 | 70,0 | 50,0 | | | Бюджеттан тыш чыганаклар, башка чыганаклар | Халыкны сыйфатлы эчәргә яраклы су белән тәэмин итү |
| 2.2.1.9 | Олы Подберезье ав-да чишмә чистарту | Олы Подберезье авыл җирлеге Башкарма комитеты (килешү буенча) | 2022 | | 40,0 | | | Бюджеттан тыш чыганаклар, башка чыганаклар | Халыкны сыйфатлы эчәргә яраклы су белән тәэмин итү |
| 2.2.1.10 | Турминский ав-да чишмә чистарту | Хуҗа Хәсән авыл җирлеге Башкарма комитеты (килешү буенча) | 2022 | | 40,0 | | | Бюджеттан тыш чыганаклар, башка чыганаклар | Халыкны сыйфатлы эчәргә яраклы су белән тәэмин итү |
| **2.2.2. Сүүткәргеч, канализация челтәрләрен һәм корылмаларны киңәйтү, реконструкцияләү һәм төзү** | | | | | | | | | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 2.2.2.1 | Мәлки авылында су үткәрү челтәрен реконструкцияләү (6 км) | Мәлки авыл жирлеге Башкарма комитеты (килешү буенча) | 2022-2023 | | 8000,0 | 7000,0 | | ТР бюджеты | Халыкны сыйфатлы эчәргә яраклы су белән тәэмин итү |
| 2.2.2.2 | Мәлки авылында янгын сүндерү гидрантлары урнаштыру (11 данә) | Мәлки авыл жирлеге Башкарма комитеты (килешү буенча) | 2021-2023 | 240,0 | 240,0 | 180,0 | | Бюджеттан тыш чыганаклар, башка чыганаклар | Янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү |
| 2.2.2.3 | Олы Урсак авылында янгын сүндерү гидрантына реконструкция (2 данә) | Олы Урсак авыл жирлеге Башкарма комитеты | 2023 | | | 120,0 | | Бюджеттан тыш чыганаклар, башка чыганаклар | Янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү |
| 2.2.2.4 | Олы Урсак авылында су үткәрү челтәрен реконструкцияләү 2,5 км | Олы Урсак авыл жирлеге Башкарма комитеты | 2022-2023 | | 1875,0 | 1875,0 | | Бюджеттан тыш чыганаклар, башка чыганаклар | Халыкны сыйфатлы эчәргә яраклы су белән тәэмин итү |
| 2.2.2.5 | Мөрәле авылында янгын сүндерү гидрантлары урнаштыру (6 данә) | Мөрәле авыл жирлеге Башкарма комитеты (килешү буенча) | 2021-2022 | 120,0 | 180,0 | | | Бюджеттан тыш чыганаклар, башка чыганаклар | Янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү |
| 2.2.2.6 | Морат авылында су үткәрү челтәрен ремонтлау | Надеждино авыл жирлеге Башкарма комитеты (килешү буенча) | 2022-2024 | | 600,0 | 600,0 | 600,0 | Бюджеттан тыш чыганаклар, башка чыганаклар | Халыкны сыйфатлы эчәргә яраклы су белән тәэмин итү |
| 2.2.2.7 | Ябалак авыл жирлегендә су үткәрү челтәрен | Ябалак авыл жирлеге Башкарма комитеты (килешү буенча) | 2021-2024 | 300,0 | 420,0 | 480,0 | 250,0 | Бюджеттан тыш чыганаклар, башка чыганаклар | Халыкны сыйфатлы эчәргә яраклы су белән тәэмин итү |
| 2.2.2.8 | Олы Тәрбит авылында янгын сүндерү гидрантлары урнаштыру (6 данә) | Чүти авыл жирлеге Башкарма комитеты (килешү буенча) | 2021-2022 | 120,0 | 180,0 | | | Бюджеттан тыш чыганаклар, башка чыганаклар | Янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү |
| 2.2.2.9 | Турминский авылында янгын сүндерү гидрантына реконструкция | Хужа Хәсән авыл жирлеге Башкарма комитеты (килешү буенча) | 2021 | 60,0 | | | | Бюджеттан тыш чыганаклар, башка чыганаклар | Янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 2.2.2.10 | Кошман авыл җирлегендә янгын сүндерү гидрантлары урнаштыру (7 данә) | Кошман авыл җирлеге Башкарма комитеты (килешү буенча) | 2021-2022 | 240,0 | 180,0 | | | Бюджеттан тыш чыганаклар, башка чыганаклар | Янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү |
| **2.2.3. Су объектларын савыктыру чаралары** | | | | | | | | | |
| 2.2.3.1 | «Чиста яр» акциясе | Район авыл җирлекләре башкарма комитетлары | 2021-2024 | 170,0 | 170,0 | 170,0 | 170,0 | Җирле бюджет | |
| 2.2.3.2 | Рус Бәрлебашы күлен төзекләндерү | Ябалак авыл җирлеге Башкарма комитеты (килешү буенча) | 2022 | | 100,0 | | | Бюджеттан тыш чыганаклар, башка чыганаклар | |
| **2.3. Җир ресурсларын, үсемлекләр дөньясы объектларын саклау һәм алардан нәтиҗәле файдалану чаралары**<br>**2.3.1. Җитештерү һәм куллану калдыкларын утильләштерү, вакытлыча саклау, күмү** | | | | | | | | | |
| 2.3.1.1 | Санкцияләнмәгән чүплекләрне бетерү | Район авыл җирлекләре башкарма комитетлары (килешү буенча) | 2021-2024 | 350,0 | 350,0 | 350,0 | 350,0 | Бюджеттан тыш чыганаклар, башка чыганаклар | |
| 2.3.1.2 | П/Э труба алу | «Кайбыч ТКХ» МУП (килешү буенча) | 2021-2024 | 150,0 | 150,0 | 150,0 | 150,0 | җирле бюджет | Торак пунктларның су үткәрү челтәрләрен санитария нормаларында тоту |
| 2.3.1.3 | Торак пунктларны санитар чистарту схемасын эшләү | Район авыл җирлекләре башкарма комитетлары (килешү буенча) | 2021-2024 | | | | | | |
| **2.3.2. Җир ресурсларын саклау һәм алардан нәтиҗәле файдалану** | | | | | | | | | |
| 2.3.2.1 | Авыл җирлекләренең яшел зоналарын төзекләндерү (саклаучы урман | Авыл җирлекләре, Кайбыч махсус орлыкчылык | 2021-2024 | 50,0 | 50,0 | 50,0 | 50,0 | җирле бюджет | Атмосфера һавасының торышын яхшырту |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | утыртмаларын һәм тулы кыйммәтле болын биоценозларын булдыру) | хуҗалыгы (килешү буенча) | | | | | | | |
| 2.3.3.2 | Санитар-яклау зоналары территориясендә, муниципаль районның торак пунктлары чикләрендә автомобиль транспорты тукталышларын-да яшел үсентеләр утырту, паркларны, скверларны төзекләндерү | Район авыл җирлекләре башкарма комитетлары (килешү буенча) | 2021-2024 | 150,0 | 150,0 | 150,0 | 150,0 | җирле бюджет | Атмосфера һавасының торышын яхшырту |
| 2.3.3.3 | Урман фондын чистарту | Район авыл җирлекләре башкарма комитетлары (килешү буенча), Кайбыч махсус орлыкчылык хуҗалыгы (килешү буенча) | 2021-2024 | 50,0 | 50,0 | 50,0 | 50,0 | җирле бюджет, башка чыганаклар | |
| **4. Халыкка экологик белем бирү, тәрбияләү һәм агарту** | | | | | | | | | |
| 4.1 | Җәйге мәктәп яны лагерьларында экологик сменалар, отрядлар оештыру | «Спорт мәктәбе» МБО, Башкарма комитетның яшьләр һәм спорт эшләре бүлеге | 2021-2024 | 150,0 | 150,0 | 150,0 | 150,0 | җирле бюджет | |
| 4.2 | Мәгълүмат-агарту чаралары, мәдәни-ял итү чаралары | Барлык авыл клублары филиаллары, авыл мәдәният йортлары, район мәдәният йорты, «Кайбыч муниципаль районы үзәкләштерелгән | 2021-2024 | 3,0 | 3,0 | 3,0 | 3,0 | җирле бюджет | Чиста су проблемаларын аңлау. Су ресурсларына сакчыл мөнәсәбәт. Туган якның сулыкларына һәм башка табигый байлыкларына аңлы мөнәсәбәт формалаштыру. Экологик фикерләүне үстерү, табигать, туган җир, |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | китапханәләр системасы» МБУ | | | | | | | илнең матурлыгын эстетик кабул итүне тәрбияләү |
| 4.3 | Тематик күргәзмәләр | Үзәкләштерелгән китапханәләр системасы | 2021-2024 | 1,5 | 1,5 | 1,5 | 1,5 | җирле бюджет | Халыкны мәгълүмати баету. Экологик тәрбия дәрәҗәсен арттыру |
| 4.4 | Массакүләм мәгълүмат чараларында экология мәсьәләләрен даими яктырту | «Кайбыч таңнары» газетасы редакциясе (килешү буенча) | 2021-2024 | 20,0 | 20,0 | 20,0 | 20,0 | җирле бюджет, башка чыганаклар | |
| 4.5 | Биологик һәм табигатьне саклау темаларына КВН, олимпиадалар, викториналар, конкурслар уздыру | Мәгариф бүлеге | 2021-2024 | 10,0 | 10,0 | 10,0 | 10,0 | җирле бюджет | |

## 6. Йомгаклау

«2021-2024 елларга Кайбыч муниципаль районында әйләнә-тирә мохитне саклау» муниципаль программасын эшләү икътисадый реформаларны дәвам итүнең кирәкле шарты булып тора.

Планлаштырылган чараларны гамәлгә ашыру район территориясендә пычраткыч матдәләр ташлауларны стабильләштерергә һәм этаплап киметә башларга мөмкинлек бирәчәк. Аерым алганда, атмосфера һавасына чыгарыла торган зарарлы матдәләрнең санын һәм күләмен 20 %ка, су объектларына зарарлы матдәләр керүне 15 %ка киметергә, халыкны яхшы сыйфатлы эчәр су белән ышанычлы тәэмин итү проблемасын хәл итәргә, җитештерү һәм куллану калдыкларын утильләштерүне һәм күмүне тәртипкә салырга, халыкның экологик белемен арттырырга, әйләнә-тирә табигать мохитен мониторинглауның нәтиҗәле системасын булдырырга.

Районда экологик вәзгыятьне савыктыру эше әлеге программа кысалары белән генә чикләнми. Җирле үзидарә органнарының билгеләнгән гамәлләре белән бер үк вакытта район предприятиеләрендә табигатьтән нәтиҗәле файдалану проблемаларын хәл итүдә комплекслы якын килү принципларын үстерергә, шулай ук халыкның табигатьтән файдалану нормалары һәм санитария-эпидемиологик иминлеге нигезендә районның социаль инфраструктурасын үстерү тәкъдим ителә.